ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 11; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 3; № 9; 2013 № 4 (I өлеш); 2014, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның беренче өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен исәпкә алып, халыкны һәм территорияләрне региональ, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеген оештыру тәртибен билгеләү һәм гамәлгә ашыруны тәэмин итү.»;

2) 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12 статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеге**

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеге халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш

хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә махсус вәкаләт тапшырылган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 6 марты
№ 11-ТРЗ